Үзәкләштерелгән дини оешма
Россия Федерациясе мөселманнары
диния нәзарәте

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

# ГЫЙД ӘЛ-ӘДХА
# (КОРБАН БӘЙРӘМЕ)
# УҢАЕННАН

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ ИДАРӘСЕ РӘИСЕ**

# МӨФТИ ШӘЕХ РАВИЛ ГАЙНЕТДИН

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

Мәскәү
Һиҗри 1445 елның
10 зөлһиҗҗә көне
Милади 2024 елның
16 июне

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

**Рәхимле, шәфкатьле**

**Аллаһ исеме белән!**

Җирдәге вә күк йөзендәге бар мәхлүкат тарафыннан макталучы, һәрнәрсәне Үз мәрхәмәте белән колачлаган галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгаләгә мактау булсын! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

**Аллаһы Тәгаләдән иминлек,**
**Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!**

**Кадерле кардәшләрем!**

Мөселман календаре буенча иң бөек көннәрнең берсе, Хаҗның тәмамлануын билгеләүче Гыйд әл-Әдха — Корбан бәйрәме җитте.

Корбан бәйрәме төрле милләттән булган, төрле тән төсендәге мөселманнарны берләштерә, ислам традицияләренә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияли. Бәйрәм тирән әхлакый мәгънәгә ия, рухи ныклык, басынкылык, мәрхәмәтлек, якыннарга мәхәббәт кебек һәр мөселман өчен кадерле мәңгелек кыйммәтләрне искә төшерә.

Бүген бар дөнья мөселманнары изге Коръән аятьләренә буйсынып, Аллаһы Тәгаләне зикер итә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ

**«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм корбан чал»**
(«Әл-Кәүсәр» сүрәсе, 2а.).

Бу көннәрдә җир йөзенең төрле кыйтгасыннан килгән Аллаһ йортына хаҗ кылучы миллионлаган кардәшебез гыйбадәт һәм корбан чалу йолаларын үтиләр, бу хакта Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында болай дигән:

ثُمَّ لْيَقْضُوا تَفَثَهُمْ وَلْيُوفُوا نُذُورَهُمْ وَلْيَطَّوَّفُوا بِالبَيْتِ العَتِيقِ

**«Үзләрен чистартсыннар, нәзерләрен үтәсеннәр һәм борынгы йортны (Кәгъбә) тәваф кылсыннар»**
(«Әл-Хәҗ» сүрәсе, 29 а.).

Шуны истә тоту мөһим: бәйрәм үзе һәм Аллаһы Тәгаләгә ризалыгы өчен Корбан чалу - ул Аллаһының чиксез нигъмәтләре өчен буйсынуны гәүдәләндерүче гыйбадәт. Ләкин корбан чалуның асылы корбанлык хайванында да, аның итендә дә түгел, бу хакта Аллаһ Үзенең Китабында болай дигән:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَى مِنكُمْ

**«Корбанга чалынган хайваннарның ите дә, каны да Аллаһка ирешәчәк түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына барып ирешә»**
(«Әл-Хаҗҗ» сүрәсе, 37 а.).

Корбан китерүнең асылы — буйсыну, диндарлык һәм тәкъвалыкта.

Бу – Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен безгә кадерле булган бар нәрсәне корбан итәргә әзер булуның символик чагылышы.

Гыйд әл-Әдха бәйрәменең тарихы пәйгамбәрләр - Ибраһим галәйһиссәлам белән аның улы Исмәгыйль галәйһиссәламнән башлана. Ибраһим пәйгамбәргә төшендә, сынау буларак, яраткан улын корбанга китерергә боерык бирелә. Сынауның авырлыгына карамастан, Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсыналар.

Ибраһим пәйгамбәр улын корбан итәргә ниятләп, яткыргач, ул шушы сүзләрне ишеткән:

يَا إِبْرَاهِيمُ قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا إِنَّا كَذَلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«И Ибраһим! Син төшеңне раска чыгардың.**
**Игелек кылучыларга Без шулай әҗерен бирәбез»**
(«Әс-саффат» сүрәсе, 104-105 а.).

Галәмнәрнең Хуҗасы һәм бернәрсәгә мохтаҗ булмаган Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне улын корбан итүдән туктаткан һәм шул рәвешле ата белән улына карата олуг мәрхәмәтен күрсәткән. Ибраһим пәйгамбәр исә безгә Раббысы кушканнарны беренчел куйган мөэмин мисалында тәкъвалык үрнәген күрсәткән. Ибраһимның җилкәсенә төшкән шундый авыр сынауны кабул итәр һәм үтәр өчен аның йөрәгендә нинди ярату, Аллаһка тапшыра белү һәм өмет булган!

Әлеге тарихта Аллаһның мөэмин-мөселманнан кеше канын түгүне таләп итмәве турында кешелек өчен үгет-нәсыйхәт бар. Киресенчә, Ул безне килешеп, татулыкта яшәргә чакыра һәм мөселманнарның сынауларга, авырлыкларга әзер булырга тиешлеген искәртә, ә авыр чакта Аллаһы Тәгалә, һичшиксез, Үзенә буйсынып, сабыр иткәннәргә Рәхмәтен ирештерә.

Ибраһим галәйһиссәлам тарихы безне Аллаһ юлында малыбыз һәм вакытыбыз белән фида кылып, Аңа гыйбадәттә һәм өммәтебезгә файдалы булырга өйрәтә.

Бу һәрберебез өчен зур гыйбрәт һәм сабак: нинди генә авырлык һәм мохтаҗлык төшсә дә, без аларны кабул итеп, ныклык һәм Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәтенә ышаныч белән җиңәргә тиеш.

Корбан бәйрәме өч көн дәвам итәчәк
һәм аның йолаларының берсе —
һәр намаздан соң Аллаһны мактап,
тәкъбир әйтү:

**اللَّهُ أَكْبَرُ اللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ**
**وَاللَّهُ أَكْبَرُ اللَّهُ أَكْبَرُ وَللهِ الْحَمْدُ**

**«Аллаһ бөек! Аллаһ бөек!**
**Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек!**
**Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактаулар булсын!»**

Шулай ук бу көннәрдә мөселманнарның бер-берсен котлавы, туганнарына кунакка баруы, бүләк өләшүе, кунак сыйлавы - күркәм гадәтләрдән. Шул ук вакытта без үз керемле һәм дин кардәшләренең игътибарына мохтаҗ булган кешеләрне дә онытырга тиеш түгел. Корбанлык ите, бәйрәм ризыгы, һичшиксез, мохтаҗларга, ялгызларга һәм ятимнәргә ирешергә тиеш.

Бүген, йөзләрчә вә меңнәрчә кардәшләребез белән бергә иңгә-иң бәйрәм намазын укыганда, без Аллаһы Тәгаләдән корбаннарыбызны кабул итүен һәм моның өчен чиксез әҗерен бирүен сорыйбыз.

Аллаһы Тәгалә кардәшләребезнең Хаҗын, чалган корбаннарыбызны, дога һәм игелекле гамәлләребезне кабул итсен! Йөрәкләребезне иманда, тәкъвалыкта, ихлас гамәлләрдә һәм яхшылыкта ныгытсын!

Без Аллаһы Тәгаләдән Ватаныбызга тынычлык һәм тотрыклылык, гаиләләребезгә иминлек һәм сәламәтлек, авыруларга шифасын һәм дәвасын, ярлыларга һәм мохтаҗларга ризык һәм муллык, гомумкешелек кардәшлеген ныгытуны сорыйбыз. Галәмнәрнең Хуҗасыннан фетнә һәм низагларны туктатуын, йөрәкләребезне үзара мәхәббәт һәм шәфкатьлелек хисләре белән тутыруын, бар кешелеккә тынычлык һәм иминлек бүләк итүен сорыйбыз.

## Гыйд әл-Әдха — Корбан бәйрәме мөбәрәк булсын!

**السلام عليكم ورحمة الله وبركاته**

***Сезнең өчен догада калып, ихтирам белән***

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин,***

***Россия Федерациясе мөселманнары диния идарәсе рәисе***